**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Гулкин авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**№27** **09.03.2021 ел**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлегенең гамәлдәге Уставы нигезләмәләрен законнарга туры китерү максатларында, Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алынганнан соң билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
4. Карар дәүләт теркәве узганнан соң һәм билгеләнгән тәртиптә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **С.Д. Инькова**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Гулкин авыл жирлеге Советының
09.03.2021 ел
27 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының
Гулкин авыл җирлеге Уставына
үзгәрешләр**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Уставына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 6 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 17 һәм 18 нче пунктларны өстәргә:

«17) полициянең участок вәкаләтлесе вазыйфасын башкаручыга һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны башкару чорына торак урыны бирү.»;

18) алкоголь, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.»;

2. 16 статьяның 9 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 7 нче пунктны өстәргә:

7) инициативалы проектны тикшерү һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.»;

3. 18.1 статьяның 6 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 4.1 нче пунктны өстәргә:

«4.1) авыл торак пунктында яшәүчеләр өчен өстенлекле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча инициативалы проект кертү турында башлангыч белән чыгыш ясарга хокуклы;»;

4. 20 статьяда:

а) 1 өлештә «һәм җирлекнең җирле үзидарә вазыйфаи затларын билгеләү» сүзләреннән соң «инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча фикер алышу,» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 5.1 өлешне өстәргә:

«5.1. Инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында уналты яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Инициативалы проектларны кертү мәсьәләләрен карау һәм тикшерү максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;

5. 22 статьяның 3 өлешен түбәндәге эчтәлекле 5.1 һәм 5.2 нче пунктлар белән тулыландырырга:

«5.1) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре инициатив проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә;

5.2) Татарстан Республикасы Законы нигезендә авыл җирлеге составына керә торган торак пункт территориясе өлешендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;»;

6. 23 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге эчтәлекле тәкъдим белән тулыландырырга: "Гражданнарның инициативалы проектка ярдәм итү турында фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча үткәрелгән сораштыруда унтугыз яше тулган инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган җирлек яисә аның өлешендә яшәүчеләр катнашырга хокуклы.»;
б) 3 өлешне түбәндәге эчтәлекле 3 нче пункт белән тулыландырырга:
"3) уналты яшькә җиткән, инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән җирлек яисә аның бер өлешендә яшәүче халык - әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.»;
в) 5 өлештә:
беренче абзацта «Җирлек Советы тарафыннан. Карарда» сүзләрен «Җирлек Советы тарафыннан. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен муниципаль берәмлекнең "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты кулланылырга мөмкин. Карарда" сүзләре белән алмаштырырга;
түбәндәге эчтәлекле 6 нчы пунктны өстәргә:
«6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнар арасында сораштыру үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе;»;
г) 7 өлешнең 1 пунктына «яисә җирлек халкын» сүзләрен өстәргә;
7. 29 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Җирлек Советы депутаты даими нигездә эшли, ул, әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан тыш, депутатлык эшчәнлеген төп эш урыны буенча хезмәтен һәм вазыйфаларын башкару белән бергә алып бара.
Үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы җирлек Советы депутатына дәвамлылыгы әлеге Уставта билгеләнгән чорга эш урынын (вазыйфасын) саклау гарантияләнә һәм, тулаем алганда, ул аена биш эш көненнән дә артык тәшкил итә алмый.»;
8. 42 статьяның 7 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7. Җирлек башлыгы хокуклы түгел:
1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек белән шөгыльләнергә;
2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә катнашырга:
а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты белән идарә итүдә, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында түләүсез нигездә катнашу;
б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итеп, коммерциячел булмаган оешма идарәсендә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты белән идарә итүдә, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек ияләре ширкәтенең гомуми җыелышында түләүсез нигездә

катнашудан тыш) түләүсез нигездә катнашу;
в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә чагылдыру (күрсәтү);
г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә, оештыручысы муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлекнең мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү, тәкъдим итү;
д) федераль законнарда каралган башка очракларда;
3) укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;
4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләре составына керергә.»;
9. 47 статьяның 9 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацларны өстәргә:
«- полициянең участок вәкаләтлесе вазыйфасын башкаручыга һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны башкару чорына торак урыны бирә.»;
- алкоголь, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыра.»;
10. 51 статьяның 2 өлешендә:
а) 1 пунктта «, шулай ук «Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль законның 82.1 статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 2 пунктта «, шулай ук Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 97.1 статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;
11. 77 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм бюджет турында закон проектын (карар) керткәннән соң кабул ителгән җирлек Советының муниципаль хокукый актлары нигезләмәләре агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә чираттагы финанс елында исәпкә алына.».